ГЛАВА ШЕЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.11.2021 с. Шеланга 11

Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Берек авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

Карар бирәм:

1. 2021нче елның 30 нчы ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Берек авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2022нче елда Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Берек авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- Берек авылында юлларны төзекләндерү һәм ремонтлау

« ӘЙЕ» « ЮК»

3. Халык җыенын Үзәк урамы, 13нче йорт янында 12.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Халык җыенын Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитеты оештыра.

5. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В.В.Майоров